ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2025 с.Старое Дрожжаное №558

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы (21.06.2019 N 505, 31.01.2020 N 54, 26.07.2021 N 645, 30.10.2021 N 1030, 09.02.2022 N 102, 01.04.2022 N 304, 20.06.2022 N 587, 14.09.2022 N 1002, 21.02.2023 N 171, 16.10.2023 N 1312, 18.06.2024 № 434, 13.09.2024 № 785, 22.04.2025 № 256, 22.09.2025 № 720 карар редакциясендә) карарының гамәлдә булуын Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларына таратырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре җитәкчеләренә:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгеләп торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренә әлеге карарда билгеләнгән хезмәт шартларының үзгәрүе турында хәбәр итәргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 30 апрелендәге 137 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Руководитель
Исполнительного комитета:                                        Р.И. Мухаметзянов